# КАРТАЯМЫНИ СОҢ ЙӨРӘК?

*САФЬЯН ИБРАҺИМОВ музыкасы*
*ГАТА НУРУЛЛИН сүзләре*

Әкрен генә, сиздермичә
Яшьлек гомере үтә.
Күңелем бер дә картаймый,
Һаман да нидер көтә.

*Кушымта:*
Картаямыни соң йөрәк,
Маңгайлар сырланса да.
Үтте яшьлек-җүләрлек, дип,
Җырларда җырланса да.

Нигә соң болай үземне
Канатлыдай хис итәм?!
Әллә яшьлегем кичләре
Әйләнеп кайтты микән?

*Кушымта.*

Мәхәббәт яшьләрдә, диләр,
Була ул һәркемдә дә.
Мәхәббәтсез яшәп булмый
Олгайган көннәрдә дә.

*Кушымта.*